| | |
|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ РАЙОН<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__03__» ____04___ 2020 г. № _140____

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл (шәһәр) җирлегенең генераль планы проекты буенча каршылыкларны җайга салу буенча Килештерү эшче төркеменең тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл (шәһәр) җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты белән килешмәү турында Җыелма бәяләмәдә билгеләнгән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының искәрмәләрен җайга салу максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына таянып, Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл (шәһәр) җирлегенең генераль планы проекты буенча каршылыкларны җайга салу буенча Килештерү эшче төркеменең тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы Балтач район башкарама комитетының 2020 елның «_3__» ___04_____ __140___ номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл (шәһәр) җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты белән килешмәү турында Җыелма бәяләмәдә билгеләнгән искәрмәләрне җайга салу буенча эшче төркем эшчәнлеге Тәртибе

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл (шәһәр) җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты белән килешмәү турында җыелма бәяләмә» әзерләү өчен нигез булган искәрмәләрне җайга салу һәм үзара риза булырлык карарлар кабул итү максатында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар нигезендә үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча карар кабул итәргә вәкаләтле орган булган Килештерү эшче төркемен (алга таба - Килештерү эшче төркеме) төзи.

2. Килештерү эшче төркеме үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Территориаль планлаштыру документлары проектларын килештергәндә муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документлары проектларын, килештерү комиссиясе составын һәм эш тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе региональ үсеш министрлыгының 2016 елның 21 июлендәге 460 номерлы боерыгына, Балтач муниципаль районы Уставына таянып эш итә.

3. Килештерү эшче төркеме үз эшчәнлеген дәүләт органнары, хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка кызыксынган затлар белән үзара хезмәттәшлектә алып бара.

4. Килештерү эшче төркеменең эш урыны булып Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Балтач ш.т.п., Ленин ур., 42 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты бинасындагы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе кабинеты тора.

5. Килештерү эшче төркеме кирәк булган саен җыела.

6. Килештерү эшче төркеменең чираттагы утырышын үткәрү датасы һәм вакыты турында эшче төркем әгъзаларына 5 көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

7. Килештерү эшче төркеменең максималь эш вакыты аны булдыру датасыннан өч айдан да артмаска тиеш.

8. Балтач муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының Килештерү эшче төркемен төзү турындагы карарын рәсми бастырып чыгару көне Килештерү эшче төркемен төзү датасы була.

9. Килештерү эшче төркеме утырышын аның рәисе, ә ул булмаганда, Килештерү эшче төркеме рәисе урынбасары оештыра һәм алып бара.

10. Килештерү эшче төркеме утырышларында эшче төркем әгъзалары катнаша, ә кирәк булганда, Килештерү эшче төркеме утырышларында гамәлдәге законнар нигезендә башка органнар вәкилләре катнаша ала.

11. Килештерү эшче төркеме утырышы, әгәр анда исемлек составының кимендә 50 проценты катнашса, хокукый көчкә ия дип санала.

12. Килештерү эшче төркеме утырышы беркетмәсенә рәис һәм секретарь кул куя.

13. Килештерү эшче төркеме тарафыннан кабул ителгән карарга каршы тавыш биргән Килештерү эшче төркеме әгъзалары аерым фикерне рәсмиләштерә алалар, ул беркетмәгә кушып бирелә һәм аның аерылгысыз өлеше булып тора.

14. Килештерү эшче төркеме карары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда Килештерү эшче төркеме рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

15. Килештерү эшче төркеменең эш нәтиҗәләре Килештерү эшче төркеменең утырышы беркетмәсендә чагыла.

16. Үзенең эш нәтиҗәләре буенча Килештерү эшче төркеме түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

16.1. Әлеге проект белән килешмәү өчен нигез булган барлык искәрмәләрне исәпкә алган үзгәрешләрне кертеп, территориаль планлаштыру документы проектын килештерергә.

16.2. Баш тарту турында карар кабул итүгә нигез булган сәбәпләрне күрсәтеп, территориаль планлаштыру документы проектын килештерүдән баш тартырга.

17. Килештерү эшче төркеме үз эшенең нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгына түбәндәгеләрне юллый:

17.1. Тәртипнең 16 пунктындагы 16.1 пунктчасында күрсәтелгән карарны кабул иткәндә, Килештерү эшче төркеме утырышы беркетмәсе, текст формасындагы һәм килештерелмәгән мәсьәләләр буенча карталар рәвешендәге материаллар белән бергә, кертелгән үзгәрешләре белән территориаль планлаштыру документы проекты.

17.2. Тәртипнең 16 пунктындагы 16.2 пунктчасында күрсәтелгән карарны кабул иткәндә, территориаль планлаштыру документының килештерелмәгән проекты, территориаль планлаштыру документы проекты белән килешмәү турында бәяләмә, Килештерү эшче төркеме утырышының беркетмәсе, шулай ук текст формасындагы һәм килештерелмәгән мәсьәләләр буенча карталар рәвешендәге материаллар.

Әлеге пунктның 17.2 пунктчасында күрсәтелгән документларда һәм материалларда түбәндәгеләр булырга мөмкин:

- килештерелмәгән мәсьәләләр буенча материалларны территориаль планлаштыру документы проектыннан төшереп калдыру турындагы тәкъдимнәр (шул исәптән, килештерү вакытына кадәр килештерелмәгән мәсьәләләрне теркәү максатларында, тиешле картада аларны чагылдыру юлы белән);

- мондый территориаль планлаштыру документына тиешле үзгәрешләрне кертү турында тәкъдимнәр әзерләү юлы белән территориаль планлаштыру документын раслаганнан соң, Тәртипнең 16 пунктындагы 16.1 пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләләрне килештерү планы.

18. Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе Килештерү эшче төркеменә тәкъдим ителгән беркетмәләр һәм материаллар нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының авыл (шәһәр) җирлеген территориаль планлаштыру документының килештерелгән яисә билгеләнгән өлештә килештерелмәгән проектын раслау өчен яисә раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерергә җибәрү өчен Татарстан Республикасы Балтач район Советына җибәрә.

19. Килештерү эшче төркеме адресына язма рәвештә килгән гаризаларга һәм гарызнамәләргә җаваплар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вакытта бирелә.

20. Килештерү эшче төркеме карарларына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.